# Нәсыйхәт

җомга
25
апрель 2011
№ 3

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы




# Файдалы үткән каникул

**Апрель аеның беренче декадасында Мамадыш мәдрәсәсе базасында балалар лагере оештырылды.**

Бу күркәм чара язгы каникул вакытына туры китерелеп эшләнде. Алты көн дәверендә төрле авыллардан килгән 16 бала мәдрәсәдә укыдылар, файдалы ял иттеләр. Әти-әниләр балалары өчен борчылмыйча тынычлап эшләде, чөнки тәрбияле, ачык йөзле, киң күңелле, һәр кешене ихтирам итә белә торган мөгаллимнәр һәм тәрбиячеләр күзәтүе астында булды балалар. Мондый эшне мәдрәсә инде өченче ел рәттән алып бара. Балалар саны елдан ел арта. Башта аларны туплау җиңел булмады. Күпчелегенә әбиләре догалар өйрәткән, кайберләре бөтенләй белми. Төрле характер, ияләштерергә кирәк. Дәреслекләр алып кайтып өләшеп, туңдырма, конфетлар, тәмле ризыклар белән чәйләр эчертеп башлады мәдрәсә ул эшне. Балалар белән очрашуга дин әһелләре, күренекле аксакаллар килде. Аларның һәммәсе дә, үзләренең тормыш тәҗрибәләреннән чыгып, вәгазь сөйләделәр, киңәшләрен әйттеләр. Мәдрәсә укытучыларының да лагерь оештыруга керткән өлешләре зур булды. Гади җөмләләр, яшәештән истә калырлык мисалларга бай чыгышлары белән балаларны авызларына каратып тордылар. Өлкәннәргә хөрмәт, әти-әнигә булган бурычлар турында сөйләделәр. Мәктәптә тырышып укырга кирәклеген, хәзерге заман яшьләре өчен белемсезлекнең никадәр авыр икәнлеген дини әхлак белән бәйләп өйрәттеләр. Лагерь мөселман әхлак нормаларына туры килүче таләпчән кагыйдәләргә нигезләнеп оештырылган. Барлык тәрбияләнүчеләр дә бишвакыт намаз укыйлар. Аларга ял итү, яхшы туклану өчен шартлар тудырылган. Мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт әйтүенчә: “Лагерь эшчәнлеге өчен тулысынча җаваплылык тәрбиячеләр җилкәсендә. Тугыз яшьтән алып ундүрт яшькә кадәр балаларга тәрбия төшенчәләрен бирү җиңел түгел. Шуның өстенә төрле гаиләдәге тәрбия биеклеген онытырга ярамый. Төрле гаиләдә төрле менталитет. Балалар, вакытлыча гына булса да, туган өйләреннән аерылып бирегә килгәннәр. Алар әти – әниләрен, туганнарын бик сагыналар. Спорт ярышлары уздырып, ислам кинолары күрсәтеп, намаз укып, призлар биреп, күчтәнәчләр белән сыйлап, күңелләрен күтәреп тордык. Тәрбияче буларак башларыннан да сыйпадык, аркаларыннан да кактык. Шелтәләргә дә туры килде. Иң мөһиме – бу эштә аеруча түземлелек һәм тагын бер тапкыр түземлелек кирәк”. Габдрахман хәзрәт фикеренчә җәйге мөселман балалар лагере ике сменалы итеп оештырырга планлаштырыла. Төрле яшьтәге мәктәп балалары биредә ислам нигезләре буенча башлангыч белем алачак. Алар Коръән укырга, гыйбадәт кылырга өйрәнәчәк. Укудан тыш, малайлар өчен спорт уеннары, походлар, «Казан Кремле» музей-ядкарьлегендә урнашкан Кол Шәриф мәчетендә, музейларда булып кайту, Нократ елгасына катерда экскурсия оештыру күздә тотыла. Быел лагерьда 50 бала ял итәр дип көтелә.

**ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА,**
**мөгаллимә.**

## Хәбәрләр

Мамадыш мәдрәсәсендә Татарстан Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе җитәкчесенең ярдәмчеләре һәм мөфтинең беренче урынбасары Абдулла Адыгамов булып киттеләр. Уку йорты директоры Габдрахман хәзрәт аларга биредә алып барылган эшләр хакында сөйләде. Кунаклар чыгышны зур игътибар белән тыңладылар, мәдрәсәдәге тату гаиләдәгечә, җылы атмосфера күңелләренә хуш килде. Очрашуда катнашучыларга үз тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен җиткерделәр: “Имамнарга мәчетләрдә террорчылыкка, экстремистлыкка каршы вәгазь сөйләүне көчәйтергә кирәк. Шулай ук мөселманнарны башка халыклар, конфессия вәкилләре белән тату һәм тыныч яшәргә өндәү аеруча мөһим”, – дип ассызыкладылар алар. Кунаклар Мамадыштагы дин торышыннан канәгать калдылар, эшчәнлек киләчәктә дә шушы юнәлештә алып барылыр дигән ышаныч белдерделәр.

Татарстан Республикасының мәдәният хезмәткәре, атказанган укытучы, язучы-прозаик, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Ганс Христиан Андерсен исемендәге премияләр лауреаты Рафаил Газизов мәдрәсә укучылары белән очрашты. Очрашу Г.Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан үткәрелде. Үзе дә 26нчы апрельдә дөньяга килгән язучы шәкертләрне Тукай тормышындагы кызыклы фактлар белән таныштырды, дөньяда барган соңгы вакыйгаларга фикерен белдерде, татар халкын, мәдәниятен, телен торгызуда һәм саклап калуда Исламның әһәмиятен һәм зур роль уйнавын билгеләп үтте.

# Ялганга корылган индустрия

**(Ахыры. Башы 25 март санында.)**

Лэкин дөнья бетү Аллаһ кына белгән биш нәрсәнең берсе",- дип җавап бирә Мөхәммәд (с.г.в.)". Шуңа күрә, чын мөселманнар мондый эшләрдән ерак булырга тиешләр. Зодиак билгеләре төшерелгән балдаклар, чылбырлар һәм башка әйберләрне йөртү дә хорафатларга ышану булып чыга. Шуңа күрә бу өлкәдән ераграк торырга тырышыгыз, йолдызнамәләр, күрәзәләр укып, вакытыгызны сарыф итмәгез.

## Исламның багучылыкка мөнәсәбәте

Багучылыкка килсәк, кайбер бәндәләр, киләчәкне Аллаһтан башка беркемнең дә белмәвен онытып, багучыларга һәм башка алдакчыларга ышаналар. Шуңа күрә сихерчеләр, им-томчылар, күрәзәчеләр бүген бик популяр. Ислам динен белмәү халыкны багучыларга китерә. Югыйсә, кыен вакытларда Аллаһка мөрәҗәгать итәргә, Аңа гына догалар кылырга кирәк. Багучылык – алдау ул. Кызганыч ки, тикшерү органнары бу өлкәдә бер статистик мәгълүмат та бирмиләр. Бүген исә меңәрләгән багучы, сихерче кеше алдалап, акча эшли. Алдау индустриясе телевидениегә дә үтеп кергән. Мәсәлән, ТНТ каналыннан "Экстрасенслар көрәше" дигән тапшыру инде бик озак бара. Анда илнең төрле төбәкләреннән "бөек талантлы" кешеләр җыела да, үзләрен яшерен нәрсәләрне белүче итеп күрсәтергә тырыша. Тамашачылар моны сәхнәләштерелгән тамаша, дип кенә кабул итсәннәр һәм аларга ышанмасыннар иде. Лэкин кайбер мөселманнар да бернәрсә дә белмиләр, шушы багучыларга, сихерчеләргә, алдакчыларга йөриләр. Алар мөселманның киләчәк язмышы хакында сорарга тиеш түгел икәнлеген оныталар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: "Язмыш хакында сөйләгәндә, сез сөйләшмисез". Шуны да аңларга кирәк, багучылык – шайтан гамәле, моның хакында Аллаһ Үзе әйтә: "Әй, иман китергән бәндәләр, дөреслектә, шәраб, отыш уеннары, потлар, багучылык - шайтан гамәлләреннән булган начар эшләр. Алардан сакланыгыз". (Маидә, 90).

Кемнәр әле һаман да багучылыкның начарлыгын аңламаган, шулар өчен тагын бер хәдис китерәм. Беркөнне Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына кешеләр килеп, аны тикшерергә теләгән. Алар кулларында бер әйберне яшерәләр дә, нәрсә бар икәнлеген сорыйлар. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) болай дип җавап биргән: "Мин багучы түгел һәм багучылык белән дә шөгыльләнмим, чөнки багучылар җәһәннәмдә яначаклар". Лэкин күп кешедә шундый сорау туа: әллә багучылар кайвакытта дөресен сөйләмиләрме? Мондый сорау сәхабәләрдә дә туган. Моңа Аллаһ илчесе болай дигән: "Аларда бер хак сүз дә юк". Алар болай диләр: "Я Аллаһ илчесе, кайвакытта бит алар дөресен дә әйтәләр". Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай ди: "Бу дөрес сүз, лэкин аны җен урлый да багучыга җиткерә, аннары багучы аңа йөз ялган сүз кушып әйтә". Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әйтимме сезгә, шайтаннар кемнәр янына киләләр? Һәрбер ялганчы янына киләләр. Аларга тыңланган хәбәрне җиткерәләр, лэкин аларның күпчелеге ялганчылар" (Шагыйрьләр, 221-223). Шулай итеп, кайвакытта сихерче әйткән сүз дөрес тә була, лэкин күктәге хәбәрне шайтаннар җиткерсеннәр өчен, аларга төрле гөнаһлар эшләргә кирәк. Сихергә һәм алар янына баручыларга килсәк, монда Аллаһ әйтә: "Кая гына барса да, сихерче бәхетсез"( Та ha, 69). Аллаһ илчесе (с.г.в.) болай ди: "Сихерчегә кылыч белән җәза бирәләр". Бу хәдисне Тирмизи җиткерә. Заманында Гомәр бөтен сихерчеләрне дә үтерергә кирәк, дигән фәрман чыгарган. Әбү Хәнифә, Мәлик, Әхмәт сихерчене үтерергә кирәк, дигән фикергә килгәннәр. Галимнәр исә Бәкара сүрәсенең 2нче аятенә таянып, сихерчене кяфер дип атыйлар. Мөселманнарга сихерчегә, багучыга бару катгый тыелган. Үзләрен сихерләгәннәр дип белеп, кайбер мөселманнар шул ук сихерчеләр янына баралар. Лэкин сихерне кайтару турында сорагач, Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Бу – шайтан гамәленең берсе", - дип җавап биргән. Өшкерүгә килсәк, анысы рөхсәт ителә.

## Юк-барларга ышану

Юк-барга ышануга килсәк, кайбер бәндәләр сынамышларга ышаналар. Мондый сүзләрне ишетергә туры килә: "юлны кара мәче кисеп үтте", "каршыга буш чиләкләр күтәргән кеше килә". Исламга хәтле чорда бөек кешеләр үлгәч, кояш һәм ай тотыла дип әйткәннәр. Пәйгамбәребезнең Ибраһим исемле улы үлгәч, кояш тотылган. Кешеләр моны Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) улы үлгәнгә дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Моны пәйгамбәр белгәч, намаз укыганнан соң, болай дигән: "Кояш белән Ай – Аллаһның билгеләре. Үлем белән туу аркасында гына кояш белән ай тотылмый". Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә мондый сүзләрне дә китергән: "Яман сынамышлар – ялган, елый торган ябалак – ялган, сәфәр аеның уңышсызлыгы – ялган" (Бохари, Мөслим). Сынамышларга ышанган кеше соңыннан боларның ялган икәнлеген ачыклый. Юк-барларга ышану кешенең акылын томалый. Югарыда әйтеп үтелгәннәргә карап, шундый нәтиҗәгә киләбез: ялганчыларга һәм сихерчеләргә каршы эш алып барырга кирәк. Ялганчы дәвалаучыларга барып, аларга җаваплылык хакында кисәтү белдерергә кирәк. Шундый бәндәләргә каршы имамнардан, хокук саклау органнарыннан һәм хакимият вәкилләреннән торган комиссия төзү мәслихәт. Алар белән аңлату эшләре алып барырга кирәк. Исламга каршы гамәлләр кылмасыннар. Шайтан тоткыны булмас өчен, аңларга кирәк: сихерчегә ышанырга-мы, яки Аллаһка өметләнергәме? Иманны мөселман гомере буена саклый. Аллаһка ышану гына бәхет, котылу китерә.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН,**
**баш мөхәррир.**

**Ф. И. О.** Ләгънәт кылынган, гөнаһ пычраклыгына баткан шайтан.
**Туу вакыты:** Күптән инде. Адәм г-м туганчы.
**Һөнәре:** Җир шарын туздыру. Аның максаты - барлык кешеләрне дә үзе белән җәһәннәмгә өстерәү, мөмкин булса, төбенә үк.
**Тору урыны:** Аллаһы Тәгаләнең исеме телгә алынмаган һәрбер йортта, барлык начар урында. Аның килүе гөнаһларга, бәхетсезлеккә, җәһәннәм газабыннан курыкмаган йөрәкләрне адашуга этәрә.
**Белеме:**
1) Кешеләргә вәсвәсә кылу, гөнаһларны рөхсәт ителгән гамәлләр шикелле матурлау буенча югары белемгә ия (магистр).
2) Кызыл җәһәннәм университеты докторы, бөтен янгыннарны кабызу буенча профессор.
3) Хатын-кызларны азат итү (бигрәк тә мөселман киеменнән) һәм моның белән ирләрнең ләззәтләнүе буенча халыкара үзәкнең баш рәисе.

**"Әй, иман китергән бәндәләр, дөреслектә, шәраб, отыш уеннары, потлар, багучылык–шайтан гамәлләреннән булган начар эшләр. Алардан сакланыгыз". (Маидә, 90).**

# Үтермә мине, әнием!

*Хатын-кызның бөтен матурлыгы, бөтен күрке ана булуда.*

**ҺАДИ ТАКТАШ.**

Ислам – гаделлек дине һәм барлык ярдәмгә мохтаҗ булган кешеләрнең хокукларын яклый. Бу дөньда барлык затның, яшьме ул, картмы, саумы яки авырумы, туган яисә якты дөньяга килергә дип яралган яралгының да, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бер бик зур хокукы– яшәүгә хакы бар. Яшәүдән мәхрүм итәргә бер кешенең дә хакы юк. Шуңа күрә ислам дине бала төшерүгә карата катгый рәвештә каршы килә: бу эш хәрам һәм зур гөнаһлардан санала. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ярлылыктан куркып, үзегезнең балаларыгызны үтермәгез, чөнки Без сезне һәм аларны ашатабыз. Күренә яки күренми торган начар эшләргә якын да килмәгез. Аллаһы кылган җанны үтермәгез. Аллаһы сезгә болай кушты, бәлки сез фикерләп эш итәрсез". Йөкне төшерүче хатын гына түгел, ә аны бу адымга этәрүче кешеләр дә гөнаһлы булалар, чөнки алар бер гөнаһсыз газиз баланы гомереннән мәхрүм итәләр. Яралгының, нинди чорда булуына карамастан, (өч атналык вакытта аның йөрәге тибә башлый) яшәргә хакы бар. Хатын-кызларга абортның зыяны турында аңлата башласаң, мең сәбәп табалар. Имеш аларның акчалары юк, йорты юк, кеше итәсе бар... Уйлап карагыз: кайсы хайван баласын үтерә, ә хатын-кыз үзе теләп бала төшерүне сорый... Мондый адымга барып, без балаларын тереләй күмүче мәҗүси гарәпләрдән нәрсә белән аерылабыз соң? «Вә тере хәлдә күмелгән кыз баладан сорасалар. Ни сәбәпле үтерелдең дип? («Ат-Тәквир», 8-9). Дин буенча саклану чараларын күрергә ярый. Тик саклану чаралары вакытлыча булырга тиеш. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә әйтеп калдырган: "Бала тудыра ала торган хатын-кызларга өйләнегез, мин кыямәт көнендә өммәтемнең күплеге белән горурланырмын." Күп кенә хатыннар йөкне төшергәннән соң төрле авыруларга дучар булалар һәм хәтта алга таба бала табу сәләтеннән дә мәхрүм калырга мөмкиннәр. Физик авырулардан тыш, аларның рухи халәтләре дә начарая, төшенкелек, тынычсызлык барлыкка килә. Йөкле хатыннар, яшь балалар күргән саен, баласын искә төшерә; төшендә, әнисе аркасында якты дөньяны күрә алмаган баласының елаганын, ярдәм сорап ялваруын күрә. Әлбәттә, бу күренеш һәр кешедә төрлечә чагылыш табарга мөмкин. Бала төшерү ислам диненә иң соңгы чиктә, ана гомеренә куркыныч янаганда гына мөмкин һәм беренче кырык көндә башкарыла. Бу очракта да ата-ана үз карамагы буенча хәл итә, чөнки күп вакытта, табиблар фаразлавына да карамастан, Аллаһының Рәхмәте белән, бала туу уңышлы үтә. Бүгенге көндә күп гаиләләр бер-ике баладан артык бала алып кайтырга куркалар. Ләкин Аллаһ Тәгалә ризыгын Үзе бирә. Илебездә ана капиталы хакында канун кертелгән һәм уңышлы гына эшләп килә. Гаиләдә бала саны күп булган саен ташламалар арта бара.



Кадерле хатын-кызлар! Аллаһның бүләгеннән баш тартмагыз, чөнки ана булу –зур нигъмәт. Аллаһның нигъмәтеннән баш тартып, без тәкъдиребезгә ризасызлык белдерәбез. Ә киләчәктә әлеге хатыннар үзләрен ялгыз картлыкка дучар итмәсләрме? Әгәр дә үз вакытында әти-әниләребез дә шулай эшләсә, без бу дөньяга килмәгән булыр идек. Бу турыда да яхшылап уйларга кирәк!

........................................

**ДАМИРА РАФЫЙКОВА,**

**табибә, 3нче курс шәкерте.**

## Алтын белән чүлмәк

Бер кеше җир сатып алган ди. Шул җирне сукалаганда алтын белән чүлмәк килеп чыккан. Чүлмәкне алып, бу кеше җирнең элекке хуҗасына киткән:

–Бу алтын белән чүлмәкне ал. Мин синнән алтын түгел, ә җирне сатып алдым,–дигән.

Элекке хуҗасы исә:

–Мин сиңа бу җирне аның байлыклары белән бергә саттым. Шуңа күрә бу алтын сиңа тиешле,–дигән.

Шулай тарткалашып торгач та, уртак фикергә килмәгәч, алар казыйга юл тотканнар. Аларны тыңлаганнан соң, казый сорау биргән:

–Сезнең балаларыгыз бармы?

Җирне сатып алучы әйткән:

–Минем бердәнбер улым бар, дигән.

Җирне саткан кеше:

–Минем бердәнбер кызым бар,–дип җавап кайтарган.

Шуннан соң казый карар чыгарган:

–Балаларыгызны өйләндерегез. Алтынның бер өлешен аларга бирерсез, ә икенче өлешен Аллаһ разый булган эшкә кулланыгыз,–дип әйткән.

# Мәдрәсәгә илткән юллар...

*Һәрбер эшләгән эшнең, һәр кылган гамәлнең үз сәбәбе бар. Белгәнебезчә, мәдрәсәбезгә төрле яшьтәге, төрле һөнәр ияләре булган хатын-кыз һәм ир-атлар белем алырга килә. Аларны бирегә нинди сәбәпләр алып килде икән? Әнә шул сорау белән мин беренче курс шәкертләренә мөрәҗәгать иттем.*

**Лилия М., укытучы:**

–Безнең икенче кызыбыз авырды һәм шул вакытта үземә урын таба алмыйча, нишләргә дә белмәдем. Бу рамазан ае иде, мин бер әбигә ураза фитрасы алып бардым. Аның белән кайгымны уртаклаштым. Үземнең күзләремнән мөлдерәмә яшьләр ага. Ул миңа болай диде: "Минем дә улым авырды, ул терелсә, намазларымны укыр идем дип, нәзер әйттем. Син дә шулай итеп кара,"- диде. Мин исә барысына да риза, балам гына терелсен. Үземнең дә дингә карата мәхәббәтем зур. Кечкенә вакыттан ук кыска догаларны белә идем. Шулай итеп мин дә намазга бастым. Барысын да яттан белмәсәм дә, беренче вакытта китаптан карап укыдым. Теләгем кабул булды: кызым терелде. Хәзер инде минем барысын да дөрес итеп, урынына җиткереп укыйсым килә. Шул сәбәпле мин мәдрәсәгә белем алырга килдем.

**Рәмзия Биктаһирова, китапханәче:**

– Мин дини календарьне ел саен алдыра идем. Андагы догалар, гарәпчә язылган аятьләр миндә зур кызыксыну уятты. Аларны өйрәнәсем килә, шуңа мин монда укырга килдем.

**Гүзәл Җиһаншина, банк хезмәткәре:**

–Мәдрәсәгә мине әнием чакырды, хәзер аның белән бергә йөрибез. Минем дини белем аласым, Коръәнне дөрес итеп укыйсым килә.

**Эльвира ХӘБИБУЛЛИНА**

**үткәрде.**

# Зирәк бала

Бер падишаһ балаларының Коръәнне ничек үзләштерүләрен белер өчен дәрескә кергән һәм шул вакыт аның игътибарын бер бала җәлеп иткән:

–Балам, укуың ничек бара? Син сыйныфның иң әйбәт укучысыдыр әле?- дип сораган.

Бала:

–Кешегә үзен-үзе мактау килешмәс,- дигән. Шуннан падишаһ укытучыдан бу бала турында сорашкан.

Укытучы:

–Бу бала бик әйбәт укый, сыйныфта беренче,- дигән.

Падишаһ кесәсеннән бер алтын тәңкә чыгарган һәм элеге балага сузган. Ләкин бала тәңкәне алырга ашыкмаган, моның өчен әтисенең орышачагын әйткән.

Шуннан падишаһ:

–Ал, ал, падишаһ бирде, диярсең, - дип, баланы үгетләмәкче булган.

Моңа җавап итеп бала:

–Падишаһ бирсә, күп итеп биргән булыр иде дип, әти миңа ышанмаячак,- дигән.

Бу сүзләрне ишеткәч, падишаһ балага уч тулы акча чыгарып бирергә мәҗбүр булган.

# Җиңүчеләр билгеле

## Газетабызның алдагы санында басылган викторина җаваплары

1.Бәдер сугышында 313 сәхабә катнашты. 2.Гәрәфә тавы. 3. Госман хәлифәлеге. 4. 624 нче елда Биләл сәхабә тарафыннан. 5. Җәрия сәдакасы (Дәвамлы сәдакалар), баланың ата -анага кылган изге догасы, үзеннән соң калган файдалы гыйлем. 6. Мөсәйлимә кәззәб. 7. Шәүвәл ае, 3 нче хиҗри ел. 8. Аллаһ 1000 фәрештә белән ярдәм итә. 9. Гайсә пәйгамбәр. 10. Әл-Кәхф сүрәсе, 50 нче аять. 11. Куба мәчете. 12.Бәккә шәһәре. 13. "Әл-Фәләкъ" һәм "ән-Нәс" сүрәләре. 14.Әл-Гәнкәбут"("Үрмәкүч"), "ән-Нәхл"("Бал корты"), "ән-Нәмл"("Кырмыска") сүрәләре. 15. Хәбил һәм Кабил. 16.Нәмрут ибн Канган. 17.Алтын бозауга табынган. 18. Коръән Хафиз. 19. Бишектә сабый чакта ("Мәрьям" сүрәсе, 30 нче аять). 20. Коръәннең 7 сүрәсе (Йосыф, Юныс, Һуд, Ибраһим, Мөхәммәд, Нух сүрәләре).

**25нче март санындагы викторина җиңүчеләре –САНИЯ ГАНИУЛЛИНА (Уразбахты авылыннан) һәм ГӨЛКӘЙ ӘГЪЛИУЛЛИНА (Мамадыш)!**

Кадерле укучыларыбыз, сезгә Ислам тематикасына кагылган яңа викторина сорауларын тәкъдим итәбез.

1.Коръәннең кайсы сүрәсендә Абраханың Кәгъбәтуллага каршы уңышсыз һөҗүме тасвирлана?

2. Ислам динен беренче кабул иткән баланың исеме.

3. Кайсы тау хакында Пәйгамбәребез: "Без аны яратабыз һәм ул да безне ярата!"- дип әйтте.

4. Кайсы агачтан җәннәт әһелләре өчен кием тегеләр?

5. Кешеләр бу дөньяда чакта ничек итеп җәннәттә күбрәк агачка ия була алалар?

6. Кайсы пәйгамбәрләрнең хатыннары җәһәннәмгә керәчәк?

7. Әлеге сүрәнең беренче аятьләрен ишетүгә, Гомәр ибн Хаттаб исламны кабул иткән. Бу нинди сүрә?

8. Адәмгә беренче булып сәҗдә кылучы фәрештәнең исеме.

9. Нух пәйгамбәрнең балаларының исемнәрен атагыз.

10. Кайсы ирекле гамәл хакында Пәйгамбәребез: "Ул гөнаһны су утны сүндергән кебек бетерә,"- дигән.

11. Үзенең кайсы сәхабәсе хакында Пәйгамбәребез:"Аның исемен җәннәтнең һәр ишеге янында әйтәчәкләр һәм минем кешеләремнән ул иң беренче булып шунда керер," –дигән.

12. Җәннәттә агучы дүрт елга нәрсә белән тулып торыр?

13. Кайсы хайваннар мәгарәгә яшеренгән Пәйгамбәребез белән Әбүбәкергә качарга булышкан?

14. Ул мәгарәнең исеме ничек?

15. Ибраһимның оныгы һәм Йосыфның атасы булган пәйгамбәрнең исемен атагыз.

**Викторинага һәм эрудитлар круизина җавапларны 12нче майга кадәр җибәрегез.**

## Шигъри дулкында

### Килер бер көн

Бу дөньяда без бары тик
Вакытлыча килгән адәм
баласы.
Күргәннәргә шөкер итеп,
Тормыш сукмагыннан
барасы.
Килер бер көн, бу сукмакта
Җилләр кубып, давыл
чыгар.
Тик иманы көчле генә
Сынмый калыр, алга атлар.
Килер бер көн, сукмак
аерылыр
Йөрәк белмәс кайсын
сайларга.
Чын ярдәмче барда гына
Дөрес юлдан язып атларга.
Килер бер көн: син
тукталырсың,
Борылып карар өчен
артыңа.
"Бу ни?"- диеп, җаның әрнер,
Кылганнарың булса
упкында.
Килер бер көн, бик тиз
килер,
Барыр юлның җитәр азагы.
Шул сукмакта булыр
котылуың,
Шул сукмакта булыр
тозагың.

.....................
**АЛЬБИНА Ш.**

**1нче курс шәкерте.**

### Килегез сез мәдрәсәгә

Укыдык без мәдрәсәдә,
Белдек анда күп нәрсәләр:
Кудык җен- шайтаннарны,
Өйрәндек без гәрәпчә дә.
Аллаһы рәхмәте иңсен
Ирек, Илнур, Габдрахман,
Ранил хәзрәтләргә!
Чакырам кардәшләремне
Гыйлем алырга мәдрәсәгә!

..............................
**ВӘКИЛ НУРМИЕВ,**

**беренче курс шәкерте.**

**Кече Сон авылы.**

# Эрудитлар круизы

**Егерме бер пәйгамбәрне эзләп табыгыз.**

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| С | Д | Ф | Ц | Щ | Я | Н | Н | Ө | Х | Ә | Ж | Ь | Ю | Ә |
| А | Д | Д | Ф | Х | Г | У | О | Ь | М | Ә | Э | Р | Э | П |
| Л | Э | М | Ы | Р | Ъ | Р | М | О | Х | Ә | М | М | Ә | Д |
| И | Ә | Ч | С | С | К | А | П | Ъ | С | С | Щ | Э | Щ | Ц |
| Х | С | Ю | О | О | Ү | Х | Л | Ф | Ө | Ы | Ч | Һ | З | Ю |
| Ъ | Й | Ь | Й | Һ | Б | Й | Ш | Д | Л | Ү | Т | Ә | Д | Н |
| З | Ә | Ъ | Ё | К | Ы | П | Ө | Ө | Р | Э | В | Й | У | Ы |
| Я | Т | Х | Ю | Г | Я | Й | К | А | Х | С | И | Щ | А | С |
| Ъ | Т | Ь | Ә | Д | М | О | С | Б | Т | Э | О | Х | Л | Э |
| Х | Ш | М | Э | А | И | Л | Р | И | С | Р | О | Ч | У | Ө |
| Я | С | О | Н | Й | А | Ю | Ь | М | Ч | Е | Ю | А | Й | Ц |
| И | Ү | З | Я | И | Р | Ә | К | О | З | О | Ъ | Ё | К | А |
| Ь | Т | М | У | С | А | Ю | Щ | Х | А | Э | А | Д | Ә | М |
| Ү | П | Ф | Э | К | Н | Г | К | У | Т | О | Җ | Э | Ю | Ә |
| И | Ь | Р | А | Һ | И | М | П | Ц | В | Г | Ч | Я | Н | Т |

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Талипов Р.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**